| | |
|---|---|
| **СОВЕТ УТЯШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӨТӘШКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2024 елның «01» апреле Өтәшкә ав. № 146

Өтәшкә авыл җирлеге Советының 2021 елның 22 июлендәге № 40 карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (Өтәшкә авыл җирлеге Советының 2022 елның 29 августында 78 номерлы, 2023 елның 23 августындагы 120 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән).

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә 2021 елның 22 июлендәге 40 номерлы Өтәшкә авыл җирлеге советы карары белән расланган (2022 елның 29 августындагы 78 номерлы, 2023 елның 23 августындагы 120 номерлы Өтәшкә авыл җирлеге Советы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Җир кишәрлекләрен тоту» бүлегенең 1 пунктындагы унөченче абзацында «, тимер юллар» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. «Тышкы яктырту объектларын (чараларын) тоту» 4 бүлегенең 7 пунктында «, иҗтимагый (тимер юл) транспортының контакт челтәре терәкләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. «Тышкы яктырту объектларын (чараларын) тоту» 4 бүлегенең 8 пунктындагы беренче абзацында «, җәмәгать (тимер юл) транспортының контакт челтәре терәге» сүзләрен;

1.4. «Тышкы яктырту объектларын (чараларын) тоту» 4 бүлегенең 9 пунктында «һәм җәмәгать (тимер юл) транспортының контакт челтәре терәкләрендә,» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында Зеленодольск муниципаль

районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында: Өтәшкә авылы, Нагорная ур., 99а йорт (җирлек администрациясе бинасы), Өтәшкә авылы, Үзәк урамы, 40а йорты (мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

Өтәшкә авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе А. А. Клопов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТ
УТЯШКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ӨТӘШКӘ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
ИНН 1620001214
ОГРН 1021606753486